ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.11.2024 г.Казань № 312-24/кс-2024

Түбән Кама муниципаль районының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 08.11.2024 ел, №24-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Татэнерго» АҖ) өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә «Татэнерго» АҖ кайнар су белән тәэмин итү өлкәсендәге җитештерү программасын расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә,

чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.11.2024 № 312-24/кс-2024
карарына 1 нче кушымта

«Татэнерго» АҖ өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | | | |
| | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк |
| | | __________________ № ___________ карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2024 кадәр | | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Татэнерго» АҖ | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | 220,00 | 205,84 | 236,99 | 222,26 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 183,33 | 171,53 | 197,49 | 185,22 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.11.2024 № 312-24/кс-2024
карарына 2 нче кушымта

| **Оешманың җитештерү программасы** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты** | | | | |
| **Җайга салынулы оешма** | «Татэнерго» АҖ | | | |
| Урнашкан урыны | 420107, Татарстан Республикасы, Казан ш., Марсель Сәлимҗанов ур., 1 й. | | | |
| **Җайга салуның вәкаләтле органы** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | |
| Урнашкан урыны | 420015, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | _________ башлап | _________________ № ________ карар үз көченә кергән көннән башлап | ___________ кадәр | 31.12.2024 |

**2 нче бүлек. Кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларын ремонтлау буенча планлы чаралар, кайнар суның сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән транспортировкада су югалтуларын киметү чаралары исемлеге**

| **№** | **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары** |
|---|---|---|---|
| | | | **2024** |
| 1ГВС – Кайнар суга тариф | | | |
| 1 | Агымдагы ремонт | мең сум | 0,00 |
| 2 | Капиталь ремонт | мең сум | 44 041,446 |
| 3 | Башка чаралар, шул исәптән кайнар суның сыйфатын яхшыртуга, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга, шул исәптән транспортировкада су югалтуларын киметүгә юнәлдерелгән чаралар | мең сум | 0,00 |

**3 нче бүлек. Кайнар су бирү күләме**

1ГВС – Кайнар суга тариф

| **№** | **Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
|---|---|---|---|
| | | | **2024** |
| 1 | Кайнар су белән тәэмин итү ихтыяҗлары өчен җылылык энергиясе күләме | Гкал | 240 052,87 |
| 1.1 | 1 куб.м. җитештерүгә җылылык энергиясе чыгымы Кайнар су белән тәэмин итү | Гкал | 0,09 |
| 2 | Кайнар су белән тәэмин итү ихтыяҗлары өчен салкын су сатып алу (җитештерү) | м3 | 3 598 201,13 |
| 2.1 | Транспортлау вакытында су югалту | м3 | 0,00 |
| 3 | Җибәрелгән кайнар су, барлыгы, шул исәптән: | м3 | 3 598 201,13 |
| 3.1 | бюджет оешмаларына | м3 | 206 000,87 |
| 3.2 | халыкка | м3 | 3 331 645,51 |
| 3.3 | башка кулланучылар | м3 | 60 554,75 |

**4 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме**

| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
|---|---|---|---|
| | | | **2024** |
| 1 | Финанс ихтыяҗлары күләме, шул исәптән: | сум | 711 945 328,26 |
| 1.1 | ЦТП башлап, кайнар су әзерләнә торган участокта абонентның һәм җайга салынулы оешманың эксплуатация җаваплылыгы чигендәге ноктага кадәр үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү системаларын карап тотуга финанс ихтыяҗлары | сум | 44 041 446,00 |
| 1.2 | Кайнар су транспортлауга бәйле чыгымнар | сум | 0,00 |
| 1.3 | Кайнар су әзерләнә торган объектлардан, шул исәптән ЦТП, алып абонентның һәм оешманың эксплуатация җаваплылыгы чигендәге ноктага кадәр участокта торбаүткәргечләрдә җылылык энергиясен югалту бәясе | сум | 0,00 |

| 5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы | | |
|---|---|---|
| **№** | **Чараның атамасы** | **план чоры** |
| 1 | Мир проспектында УТ-11 башлап УТ-12 кадәрге участокта ЦТП-76 башлап кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен капиталь ремонтлау | 2024 елның сентябре-декабре |
| 2 | ЦТП-10 башлап кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен капиталь ремонтлау, түбәндәге участокларда: Корабельная урамы, 20а торак йорттан башлап 16 нчы балалар бакчачына кадәр Корабельная урамы буенча, 20б йорт, 14 нче балалар бакчасына кадәр, Юность урамы, 24а, Юность урамы, 26 торак йортка кадәр; Юность урамы, 24 алып ТК-3 кадәр; ТК-3 алып, Юность урамы, 20а кадәр; ТК-3 алып, Юность урамы, 22 кадәр; Юность урамы, 22 башлап, Юность урамы, 20 кадәр; Юность урамы, 24 алып, Юность урамы, 26 кадәр; Корабельная урамы, 20а алып Корабельная, 20 кадәр | |
| 3 | ЦТП-9 башлап кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен капиталь ремонтлау, түбәндәге участокларда: ТК-10 башлап УТ-2 кадәр; ТК-11 башлап УТ-2 кадәр; ТК-11 башлап 6 нчы мәктәпкә кадәр; ТК-12 башлап пед. училищега кадәр | |
| 4 | ЦТП-33 башлап кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен капиталь ремонтлау, түбәндәге участокларда: ТК-1 башлап Химиклар проспектындагы 104, 106, 110 номерлы торак йортларга кадәр | |
| 5 | ЦТП-67 башлап кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен капиталь ремонтлау, түбәндәге участокларда: ЦТП башлап, Мир урамы буенча 17 йорт адресында УТ-5а кадәр; УТ-5а башлап 26 нчы гимназиягә һәм 75 нче балалар бакчасына кадәр | |
| 6 | ЦТП-74 башлап кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен капиталь ремонтлау, түбәндәге участокларда: ЦТП башлап ТК-2 кадәр; ТК-1 башлап, Бакый Урманче, 33 тимер юлга кадәр; 31 номерлы торак йорттан Бакый Урманчы урамындагы 33 нче торак йортка кадәр; ТК-2 алып, Мир проспекты буенча 29 нчы мәктәпкә кадәр; ТК-3 башлап, Мир проспекты буенча 75 нче торак йортка кадәр | |
| 7 | ЦТП-65 башлап кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен капиталь ремонтлау, түбәндәге участокларда: ЦТП башлап, Лесная урамындагы 27 торак йортка кадәр; ТК-2 башлап, Химиклар проспекты буенча 95 торак йортка кадәр; ТК-1 башлап, Химиклар проспектында 93а адресы буенча 66 нчы балалар бакчасына кадәр; ТК-3 башлап, Химиклар проспекты буенча 97 торак йортка кадәр | |

| 6 нчы бүлек. Кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфат күрсәткечләренең план күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|
| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2024** |
| 1ГВС – Кайнар суга тариф | | | |
| 1 | Кайнар суның сыйфат күрсәткечләре | | |
| 1.1 | Җылылык челтәрендә яисә кайнар су белән тәэмин итү челтәрендә температура буенча билгеләнгән таләпләргә туры килми торган кайнар су пробаларының кайнар су сыйфатын производствода тикшереп тору нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендәге өлеше | % | 0,00 |
| 1.2 | Җылылык челтәрендә яисә кайнар су белән тәэмин итү челтәрендә кайнар су сыйфатын производствода тикшереп тору нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә билгеләнгән таләпләргә (температурадан тыш) туры килми торган кайнар су пробалары өлеше | % | 0,00 |
| 2 | Су агызуның ышанычлылык һәм өзлексезлек күрсәткечләре | | |
| 2.1 | Сүүткәргеч челтәренең бер елга озынлыгын исәпләгәндә кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмага караган үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү системасы объектларындагы аварияләр, зарарланулар һәм башка технологик хокук бозулар нәтиҗәсендә кайнар су белән тәэмин итү буенча кайнар су белән тәэмин итү оешмасы йөкләмәләрен үтәү урыннарында теркәлгән су бирүдәге өзеклекләр саны | бер./км | - |

| 7 нче бүлек. Кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфат күрсәткечләренең һәм җитештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының пландагы күрсәткечләрен аның гамәлдә булу срогы дәвамында үзгәртү динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләп чыгару |
|---|

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | **2024** |
| 1ГВС – Кайнар суга тариф | | | |
| | Үзгәреш динамикасын чагыштыру | % | Оешма 2022 елда кайнар су белән тәэмин итү эшчәнлегенең җайга салынулы төрен тормышка ашырмады. |
| **8 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап** | | | |
| Оешма 2022 елда кайнар су белән тәэмин итү эшчәнлегенең җайга салынулы төрен тормышка ашырмады. | | | |
| **9 нчы бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар** | | | |
| | Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган. | | |